КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 27 ноябрь г.Казань № 1067

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 31 декабрь, 1086 нчы карары белән расланган «Татарстан Республикасының төзелеш комплексы» дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының төзелеш комплексы» дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәне һәм «Татарстан Республикасының төзелеш комплексы» дәүләт мәгълүмат системасында катнашучыларның мәгълүмати хезмәттәшлеге регламентын раслау хакында» 2016 ел, 31 декабрь, 1086 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 7 август, 955 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасының төзелеш комплексы» дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7.2 пунктта татар текстында «федераль законнар» сүзләреннән соң «һәм Россия Федерациясе Президенты актлары» сүзләрен өстәргә;

7.3 пунктның өченче абзацында «законнар» сүзләреннән соң «һәм Россия Федерациясе Президенты актлары» сүзләрен өстәргә;

7.9 пунктның икенче абзацында татар текстында «федераль законнар» сүзләреннән соң «һәм Россия Федерациясе Президенты актлары» сүзләрен өстәргә;

7.10 пунктның дүртенче абзацында татар текстында «федераль законнар» сүзләреннән соң «һәм Россия Федерациясе Президенты актлары» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин